СОВЕТ ТОЙГУЗИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МЕНДЕЛЕЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МЕНДЕЛЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ТОЙГУҖА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

---

**Р Е Ш Е Н И Е** **К А Р А Р**

07.07. 2023 ел № 84

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы «Тойгуҗа авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирле салымнар суммалары өлешендә бурычны түләтүгә ышанычсыз дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләү турында

Россия Федерациясе Салым кодексының 59 статьясындагы 3 пункты, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы « Тойгуҗа авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставы нигезендә,

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Тойгуҗа авыл җирлеге Советы **карар кылды**:

1. Җирле салымнар суммалары өлешендә бурычны түләтүгә ышанычсыз дип тануга өстәмә нигезләр билгеләргә:

1) физик затның вафат булган көненнән яисә аны граждан-процессуаль законнарында билгеләнгән тәртиптә вафат булган дип игълан иткән көннән соң, әгәр варислар закон буенча да, васыять буенча да булмаган булса, йә варисларның берсенең дә мирас итеп алырга хокукы булмаса яисә барлык варислары варислардан читләштерелгән булса, йә варисларның берсе дә мирасны кабул итмәгән, йә барлык варислар мирастан баш тарткан һәм шул ук вакытта аларның берсе дә башка варис файдасына баш тартуын күрсәтмәгән булса;

2) салым түләүче - гражданнарның стационар социаль хезмәт күрсәтүне гамәлгә ашыручы оешмада физик затның булуы;

3) салым салу объекты булган мөлкәткә милек хокукы туктатылган көннән соң өч еллык срок узу;

4) юкка чыгарылган җирле салымнарны һәм җыемнарны түләү бурычы барлыкка килгән көннән соң өч ел вакыт узгач;

5) физик затларның җирле салымнар буенча бурычы барлыкка килгән көннән аларны исәптән чыгару турында карар кабул ителгән көнгә аларның күләме 100 (йөз) сумнан артмаган, салым түләүченең бөлгенлек (банкротлык) турындагы эштә кулланыла торган процедураларда катнашмаган очракта;

6) «бөлгенлек (банкротлык) турында» 2002 елның 26 октябрендәге 127-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә гражданны банкрот дип тану - күрсәтелгән Федераль закон нигезендә кредиторлар белән исәп-хисапларны тәмамлау йомгаклары буенча түләнмәгән һәм күрсәтелгән Федераль законның 5 статьясы нигезендә агымдагы түләүләргә караган җирле салымнар буенча бурыч өлешендә;

7) «Россия Федерациясендә өлешчә мобилизацияләү турында» Россия Федерациясе Президентының 2022 елның 21 сентябрендәге 647 номерлы Указы буенча җирле салымнар буенча 2022 елның 1 сентябренә бурыч өлешендә салым түләүчене мобилизацияләү, әмма аларны исәптән чыгару турында карар кабул ителгән көнгә җирле салымнар буенча шундый бурыч күләменнән артмый.

2. Тойгуҗа авыл җирлеге Советының 2021 елның 1 июнендәге 27 номерлы җирле салымнар буенча бурычларны, пенялар һәм штрафлар буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләре турында карары үз көчен югалткан дип танырга

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталына урнаштырып игълан итәргә http://pravo.tatarstan.ru һәм Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында “Тойгуҗа авыл җирлеге" бүлегендә урнаштырырга www.mendeleevsk.tatar.ru

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Тойгуҗа авыл җирлеге Советы рәисе Р.А. Сафин